**Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Биклән авыл җирлеге составына керүче Биклән авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

**КАРАР**

20 октябрь 2023 ел № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2023 елның 19 нчы, 20 нче октябрендә узган гражданнар җыеннары нәтиҗәләре белән түбәндәге мәсьәлә буенча гражданнар җыены беркетмәсе тәзелде:

«2024 елда яшәү урыны буенча Биклән авыл җирлеге Биклән авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә 500 (биш йөз) сум күләмендә бер тапкыр түләү кертергә һәм I, II төркем инвалидлары һәм Бөек Ватан сугышы ветераннары, ялгыз яшәүче өлкән яшьтәге гражданнар һәм көндезге формада укучы студентлар, күп балалы гаиләләр өчен бер тапкыр түләү күләмен киметергә һәм аны әлеге категория гражданнар өчен 300 (өч йөз) сум күләмендә билгеләргә, әлеге сумманы түбәндәге мәсьәләне хәл итүгә юнәлдерергә Сез ризамы:

- масса-күләм спорт белән шөгыльләнү өчен спорт инвентарьлары сатып алу;
- халыкның мәдәни ялын оештыру (халыкның үзешчән сәнгатьтә катнашуы өчен музыкаль аппаратура һәм сәхнә костюмнары сатып алу);
- Биклән авылы эчендәге юлларны, китереп бирү ысулы белән,вак таш (щебень) сатып алып,төзекләндерү;
- Биклән авылы урам яктылыгы өчен энергия саклаучы яктырткычлар һәм электр товарлары сатып алу;
- сугыш хәрәкәтләрендә катнашучылар хөрмәтенә архитектура-скульптура корылмасы элементларын сатып алу.

**“ӘЙЕ”** **“ ЮК”**

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында катнашучы 1117 кеше кертелде, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны – 574 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча җыенда катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен гражданнар җыенында катнашучы 571 кеше тавыш бирде;

«Юк» позициясе өчен җыенында катнашучы 3 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Биклән авыл җирлеге Биклән авылында гражданнар җыенын узган, гражданнар җыены нәтиҗәләрен гамәлдә дип танырга.

2. «2024 елда яшәү урыны буенча Биклән авыл җирлеге Биклән авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә 500 (биш йөз) сум күләмендә бер тапкыр түләү кертергә һәм I, II төркем инвалидлары һәм Бөек Ватан сугышы

ветераннары, ялгыз яшәүче өлкән яшьтәге гражданнар һәм көндезге формада укучы студентлар, күп балалы гаиләләр өчен бер тапкыр түләү күләмен киметергә һәм аны әлеге категория гражданнар өчен 300 (өч йөз) сум күләмендә билгеләргә, әлеге сумманы түбәндәге мәсьәләне хәл итүгә юнәлдерергә Сез ризамы:
- масса-күләм спорт белән шөгыльләнү өчен спорт инвентарьлары сатып алу;
- халыкның мәдәни ялын оештыру (халыкның үзешчән сәнгатьтә катнашуы өчен музыкаль аппаратура һәм сәхнә костюмнары сатып алу);
- Биклән авылы эчендәге юлларны, китереп бирү ысулы белән,вак таш (щебень) сатып алып,төзекләндерү;
- Биклән авылы урам яктылыгы өчен энергия саклаучы яктырткычлар һәм электр товарлары сатып алу;
- сугыш хәрәкәтләрендә катнашучылар хөрмәтенә архитектура-скульптура корылмасы элементларын сатып алу.

3. Тукай муниципаль районы Биклән авыл җирлеге Биклән авылы гражданнар җыены нәтиҗәсен авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырып, халыкка җиткерергә.

4. Тукай муниципаль районы Биклән авыл җирлеге Биклән авылы гражданнар җыены нәтиҗәсен Тукай муниципаль районының рәсми сайтында «авыл җирлекләре» бүлегендә, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Биклән авыл җирлеге Башлыгы — М. Ш. Сәхбеев